РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

***Постановление*** **___26.02.2025____** **г. Чистополь** ***Карар*** **№__42__**

Хайваннарны хуҗаларыннан һәм
хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү
урыннарына кайтару турында карарлар
кабул итәргә вәкаләтле затлардан башка
кайтару тыела торган урыннар исемлеген
раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Чистай шәһәр Башкарма комитеты Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Хайваннарны хуҗаларыннан һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итәргә вәкаләтле затлардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары хуҗасыз хайваннарны хуҗасыз хайваннар яши торган элеккеге урыннарына кайтару турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле булып тора.
3. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Хайваннарны хуҗаларыннан һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау турында» 2022 елның 9 сентябрендәге 146 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәр Башкарма
комитетының
_26.02.2025__ ел, № _42_
карары белән
расланды

Хайваннарны хуҗаларыннан һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле затлардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

1. Балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, ял базалары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.

6. Транспорт инфраструктурасы объектлары (автовокзаллар, автостанцияләр, автобус тукталышлары).

7. Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүнең җитештерүчән булмаган төрләре объектлары (мунчалар һәм сауналар).

8. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

9. Күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.

10. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.